**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**УРЮМСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**УРЮМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

тел. (84373) 54-0-38, факс 54-0-38

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**19 .11. 2021** **№ 5**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Богдашкино Урюм авыл җирлегенең Богдашкино торак пунктында 2022 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Урюм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 ст. нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Богдашкино авылы, Совет урамы, 16 нчы йорт адресы буенча урнашкан Богдашкино авыл мәдәният йорты бинасында 2021 елның 3 декабрендә 11 сәгать 00 минутта, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Урюм авыл җирлегенең Богдашкино торак пунктында 2022 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Богдашкино авылы, Совет урамы, 16 нчы йорт адресы буенча урнашкан Богдашкино авыл мәдәният йорты бинасында 2021 елның 3 декабрендә 13 сәгать 00 минутта, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Богдашкино авыл җирлегенең Богдашкино торак пунктында 2022 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2022 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Богдашкино Урюм авыл җирлеге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, көндезге уку формасы буенча укучы студентлар, күп балалы гаиләләр, I төркем инвалидлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәт итәргә чакырылган гражданнар, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы гражданнардан тыш, 1500 сум күләмендә акча кертергә килешәсезме?, - алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү:

-авыл эчендәге юлларны төзекләндерү (вак таш, ком сатып алу, җир полотносын төшерү, нигез әзерләү, ташу, җәю, трамбовка, эшләр, хезмәтләр өчен түләү) буенча Богдашкино т. п. Ленин урамы, Пролетарская урамы буенча юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү;».

«КАРШЫ» “РИЗА”

4. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Урюм авыл җирлеге башкарма комитеты Гражданнар җыенын оештырырга һәм үткәрергә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Урюм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга. https://tetushi.tatarstan.ru/

6. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Урюм авыл җирлеге башкарма комитеты Гражданнар җыенын үткәргәндә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Урюм авыл җирлеге территориясендә яңа коронавирус йогышы (COVID-19) белән авыру очракларын кисәтү һәм тарату өчен профилактик, санитар-эпидемиологик чараларның үтәлешен тәэмин итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Җитәкче урынбасары** **А. В Леденейкин**